БУГУЛЬМИНСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
IV СОЗЫВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БӨГЕЛМӘ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
IV ЧАКЫРЫЛЫШ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

от 13.12.2023г. г. Бугульма № 4

**ЕГЕРМЕ ӨЧЕНЧЕ СЕССИЯ**

**«Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Бөгелмә шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турында» яңа редакциядәге нигезләмәгә - Бөгелмә шәһәр Советының 2021 елның 19 апрелендәге VII сессиясенең 3 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Бөгелмә шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы һәм җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларын законнарга туры китерү максатларында

Бөгелмә шәһәр Советы

Карар кабул итте:

1. Бөгелмә шәһәр Советының 2021 елның 19 апрелендәге VII сессиясенең 3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Бөгелмә шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1) 3.1 нче өлештә:

а) 30 нчы пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

"30) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм

законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, Бөгелмә шәһәре муниципаль берәмлегендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

б) түбәндәге эчтәлектәге 41 нче пункт белән тулыландырырга:

"41) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм мондый зыянны бетерүне Бөгелмә шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата оештыру;»;

2) 5 нче өлештә:

а) 11 нче пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«11) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, Бөгелмә шәһәре муниципаль берәмлегендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

б) 3 нче пунктны түбәндәге эчтәлектәге 10 нчы пункт белән тулыландырырга:

“- Бөгелмә шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм мондый зыянны бетерүне оештыру;".

2. Әлеге карар үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Бөгелмә шәһәре муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртиптә бастырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бөгелмә шәһәре мэры урынбасары И.Б. Беловага йөкләргә.

**Бөгелмә шәһәре мэры Л. Р. Закиров**